КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 сентябрь г.Казань № 1068

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге Республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 25 май, 298 нче; 2018 ел, 21 май, 384 нче; 2019 ел, 25 гыйнвар, 38 нче; 2020 ел, 12 март, 187 нче; 2020 ел, 21 сентябрь, 850 нче; 2021 ел, 15 февраль, 81 нче; 2021 ел, 21 июль, 636 нчы; 2021 ел, 23 октябрь, 998 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 945 нче, 2023 ел, 23 май, 628 нче, 2023 ел, 17 июль, 840 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында нигезләмәнең 12 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

күрсәтелгән карар белән расланган Г.Р.Державин исемендәге Республика премиясе комитеты составында:

Комитет составыннан М.Х.Салаховны чыгарырга;

Комитет составына «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты Миңнеханов Рифкать Нургали улын кертергә;

Миңзарипов Рияз Гатаулла улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе президенты (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин